КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 октябрь г.Казань № 1319

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 апрель, 263 нче; 2021 ел, 13 сентябрь, 870 нче; 2022 ел, 31 август, 927 нче; 2022 ел, 29 декабрь, 1455 нче; 2023 ел, 27 май, 646 нчы; 2023 ел, 2 октябрь, 1204 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Программа максатын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләре» юлындагы өченче абзацында «матди һәм матди булмаган мирасының өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган объектлары» сүзләрен «матди мәдәни мирасының һәм матди булмаган этномәдәни байлыгының өйрәнелгән һәм популярлаштырылган объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның I бүлегендәге алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Германия, Польша, Бөекбритания, Япония, Италия, Төркия, Үзбәкстан, Казакъстан архивларыннан татарларның тарихы һәм мәдәнияте буенча ике меңнән артык яңа документ ачыкланды, татар халкының матди мәдәни мирасы һәм матди булмаган этномәдәни байлыгының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән, күп кенә билгесез фактларны, тарихи вакыйгалар, танылган шәхесләр турындагы мәгълүматларны ача торган меңнән артык сирәк һәм уникаль документлар сканерланды. Кайбер очракларда документларның төп коллекцияләрен Татарстан Республикасы архивларына һәм музейларына (Кобе шәһәренең татар җәмгыяте архивына, Коръәннең Токия басмасын) тапшыруга ирешелде.»;

Программага 1 нче кушымтада:

«Татарларның тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү, популярлаштыру һәм саклау чараларын оештыру» юлының 4 графасында «матди һәм матди булмаган мирасының өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган объектлары» сүзләрен «матди мәдәни мирасының һәм матди булмаган этномәдәни байлыгының өйрәнелгән һәм популярлаштырылган объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1.3. «Рухи мирас» басмасы сериясендә «Мирасханә» архив материалларын халык алдында тапшыру | ТР ФА, Г.Ибраһимов ис. ТӘСИ | 2020 – 2025 еллар | Татарларның тарихына һәм мәдәниятенә багышланган фәнни, фәнни-популяр яисә белешмә басмалар саны («Мирасханә» архив материаллары), берәмлек | - | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 1 407,19 | 1 477,59 | 1 477,5 | 1 718,49 | 1 718,49 | 1 718,49»; |
| | | | «Рухи мирас» дигән бер басманың тиражы, нөсхә | - | 500 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | | | | | | |
| | | | «Мирасханә» рәсми сайтында урнаштырылган басмалар саны, берәмлек | - | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | | | | | | |

1.4 пунктның 4 графасында «өйрәнелгән, Miras.info порталында әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы объектлары һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның «Татарларның өйрәнелгән, әйләнешкә керетлгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары (музыкаль шкатулкалар) саны, берәмлек» дигән өстәмә юлындагы 4 графасында «өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.10 пунктның «Татарларның өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары (татар эпиграфия ядкарьләре) саны, берәмлек» дигән юлындагы 4 графасында «өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.15 пунктның «Татарстан Республикасыннан читтә татарларның өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары саны, берәмлек» дигән өстәмә юлындагы 4 графасында «өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы

объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы объектлары һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.16 пунктның «Татарларның Укек шәһәрлеге һәм аның округы территориясендә табылган, өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары саны, берәмлек» дигән юлындагы 4 графасында «өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы объектлары һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

1.18 пунктның «Татарларның Урта гасыр Урта Азия һәм Кавказ арты территориясендә табылган, өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары саны, берәмлек» дигән өстәмә юлындагы 4 графасында «өйрәнелгән, әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы объектлары һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.6. Татар дин әһелләренең ел саен уздырыла торган «Милли үзенчәлек һәм дин» бөтенроссия форумын үткәрү | ТР ММ, БТК (килешү буенча), ҮМДН (килешү буенча), ТР МДН (килешү буенча), ТР МБСА (килешү буенча) | 2021 – 2025 еллар | Татарлар күпләп яши торган төбәкләрнең гомуми санында татар дин әһелләре форумында катнашкан Россия Федерациясе төбәкләре өлеше, процент | 85 | - | 85 | 85 | 85 | 85 | 85 | - | 4 985,0 | 4 985,0 | 6 905,0 | 4 985,0 | 4 985,0 |
| | | | Татар дин әһелләренең «Милли үзенчәлек һәм дин» бөтенроссия форумында катнашучылар саны, кеше | 900 | - | 900 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | 1 000 | | | | | | |

2.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «2.10. «Әпипә» бөтенроссия телевизион татар халык биюе конкурсын үткәрү, шул исәптән биючеләргә өйрәтү буенча мастер-класслар үткәрү | ТР ММ, БТК (килешү буенча), «ТНВ» ТРК (килешү буенча) | 2021 – 2025 еллар | «Әпипә» бөтенроссия телевизион татар халык биюе конкурсында катнашучылар саны, кеше | - | - | 350 | 355 | 120 | 365 | 370 | - | 2 800,0 | 2 800,0 | 880,0 | 2 800,0 | 2 800,0»; |
| | | | Телевизион чыгарылышлар саны, берәмлек | - | - | 20 | 20 | 6 | 20 | 20 | | | | | | |

3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3.12. Сәнгатьле укучыларның «Җәлил укулары» халыкара әдәби конкурсын үткәрү | ТР ММ, БТК (килешү буенча) | 2021 – 2025 еллар | Сәнгатьле укучыларның «Җәлил укулары» халыкара әдәби конкурсында катнашучылар саны, кеше | - | - | 10 000 | 10 000 | 30 000 | 35 000 | 35 000 | - | 2 374,1 | 2 374,1 | 2 556,4 | 2 556,4 | 2 556,4»; |

4.4 пунктның 4 графасында «өйрәнелгән, Tatfolkfound порталында әйләнешкә кертелгән һәм популярлаштырылган матди һәм матди булмаган мирасы объектлары» сүзләрен «өйрәнелгән һәм популярлаштырылган матди мәдәни мирасы объектлары һәм матди булмаган этномәдәни байлыгы объектлары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин